УДК 792.09

***Е.Н. Шевченко***

# ТАТАРСТАНДА БЭБИ-ТЕАТР

Статья посвящена бэби-театру – достаточно новому явлению отечественной театральной культуры. Речь идет об интерактивном театре для детей с самого раннего возраста до трех лет. Цель статьи состоит в том, чтобы выявить его жанровые признаки, провести водораздел между бэби-театром и анимацией, представить картину его бытования в Татарстане. В статье рассматривается история возникновения и распространения бэби-театра в республике, приводятся показательные примеры спектаклей этого направления. Сделанные в ходе работы наблюдения показывают: в отличие от анимации, направленной на развлечение и организацию детского досуга, бэби-театр имеет своей целью эмоциональное и эстетическое развитие ребенка, его знакомство с окружающим миром. Будучи бессюжетным, бесконфликтным и бестекстовым, он при этом обращается к темам, важным для формирования личности ребенка, и одновременно знакомит его с языком театра и его устройством. Практические результаты исследования могут быть использованы в деле дальнейшего развития в Татарстане этого важного сектора театрального искусства.

**Ключевые слова:** бэби-театр, интерактивный театр, Алмаз Садриев, Всероссийский фестиваль бэби-театров «Лэклэк»

The article is devoted to baby theater – a fairly new phenomenon of Russian theater culture. We are talking about an interactive theater for children from a very young age to three years old. The purpose of the article is to identify its genre characteristics, to draw a watershed between baby theater and animation, to present a picture of its existence in Tatarstan. The article examines the history of the emergence and distribution of baby theater in the republic, provides illustrative examples of performances in this direction. Observations made during the work show: unlike animation aimed at entertaining and organizing children's leisure, baby theater aims at the emotional and aesthetic development of the child, his acquaintance with the world around him. Being plotless, conflict-free and textless, he addresses topics important for the formation of the child's personality, and at the same time introduces him to the language of the theater and its structure. The practical results of the study can be used in the further development of this important sector of theatrical art in Tatarstan.

Keywords: baby theater, interactive theater, Almaz Sadriev, All-Russian festival of baby theaters "Leklak"

Соңгы елларда балалар театрының яшь чикләре киңәя бара. Әйтик, Россиядә бэби-театр гадәттән тыш популярлык казанды. Бэби-театр тарафдарлары фикеренчә, баланы тууга театр белән таныштыра башларга кирәк. Элек кабул ителгәнчә, нәни тамашачының аңлау механизмнары эшкә җигелеп, логик фикерләве үсеш алган өчдүрт яшькә җитүен көтәргә кирәкми. Сабыйлар өчен интеллектуаль үсештән бигрәк эмоциональ һәм эстетик үсеш мөһим дип уйлый алар. Бэби-театр – балаларны әйләнә-тирә дөнья белән таныштыруга

юнәлдерелгән интерактив театр. Ул әзер текстларга һәм сценарийларга таянмый: төп игътибар фабулага түгел, ә тасвирый-тәэсир итү чараларына – музыкага, яктылык, хәрәкәт, төсләр гаммасы, тактиль тойгылар, исләргә бирелә. Шул рәвешле балалар дөньяны төрле ысуллар ярдәмендә кабул итә ала. Яңа тәҗрибәгә ия булсыннар дип, аларда вакыйгаларга актив кушылып китү теләге тудыралар. Сюжетсыз һәм конфликтсыз булуына карамастан, бэби-театр тирән һәм катлаулы темаларга мөрәҗәгать итә ала. Сәнгатьчә рәвеш алып, тылсымлы атмосферада, сабыйларга аңлаешлы телдә бара. Бер үк вакытта нәниләр театр дөньясы, аның төзелеше белән танышалар, тамашачы буларак беренче тәҗрибәләрен туплыйлар. Шул ук вакытта биредә аларның үзләрен «өйдәге кебек» уңайлы һәм иркен хис итүләре мөһим.

Европада нәниләр өчен театрлар XX гасырның 70 нче елларында ук барлыкка килә. Бэби-театр пионерларының берсе – Италия режиссёры Роберто Фрабетти. Ул ачып җибәргән «La Baracca – Testoni Ragazzi» театры Европа илләрендә берничә ел дәвамында «Кечкенә үлчәм – зур гражданнар» программасын гамәлгә ашыра. Россиягә бу хәрәкәт 2000 елга гына килеп җитә, Татарстанда исә беренче бэби-спектакльләр 2017–2018 елларда, ягъни чама белән ун ел элек барлыкка килә. Республикабызда бэби-театрның барлыкка килүе һәм үсеше режиссёр, актёр, драматург Алмаз Садриев исеме белән бәйле. Театр тәнкыйтьчесе, балалар театры белгече Марина Шимадина билгеләп үткәнчә, «это тот показательный случай, когда целое направление театра в регионе запустил, по сути, один человек» [4]. Нәниләр өчен театр белән Алмаз Садриев 2015 елда Мейерхольд исемендәге Мәскәү үзәге «Театр лидеры мәктәбе»нең белем бирү программасы белән танышкач шөгыльләнә башлый. Аннары ул Театр эшлеклеләре берлеге һәм Театр институты тарафыннан Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә үткәрелгән «Бэби Лаб» проектының барлык лабораторияләрендә катнаша, чит илләрдәге хезмәттәшләренең тәҗрибәсен өйрәнә. Яңа идеяләр һәм белемнәр белән рухланган А. Садриев республика театрларында да аларга карата кызыксыну уятырга тырышып карый. Тегеләр башта яңа башлангычка скептикларча карыйлар, әмма режиссёрның үзсүзлелеге, ышандыру көче һәм теоретик яктан көчле булуы акрынлап шикләнүләрне юкка чыгара, Татарстанда да, күрше төбәкләрдә дә нәниләр өчен театрның зәгыйфь кенә үсентеләре күренә башлый [4].

Бүгенге көндә Алмаз Садриев – «Small size» дип исемләнгән нәниләр өчен театрларның Европа ассоциациясе әгъзасы, Татарстанда беренче «Small Art» бэби-театрына нигез салучы, бэби-театрга багышланган иҗади лаборатория һәм фестивальләрнең даими катнашучысы, Россиядә бэби-спектакльләр куючы режиссёрларның берсе, «Калабала» нәни тамашачылар өчен башкару сәнгате ассоциациясе җитәкчесе. Ул – Россиядә бэби-театр юнәлешен эзлекле һәм максатчан үстерүче театр эшлеклесе. Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә филология, психология, режиссура һәм менеджмент буенча белем алган

Алмаз Садриев бу феноменны төрле яктан тикшерә, яңа алымнар уйлап табып, театр телен камилләштереп, тәҗрибә туплый. Төп максатны ул баланың сәнгать аша рухи үсешендә күрә.

Татарстанда бэби-театрны беренчеләрдән булып Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры ачты. 2018 елда нәкъ менә шунда Алмаз Садриевның беренче милли бэби-спектакле – «Татар орнаменты. Тере бизәкләр» куела. 17 мең кеше яшәгән нәкъ менә шушы шәһәрчектә 2021 елда Small Size Days бөтендөнья акциясе кысаларында «Ләкләк» I иҗади белем бирү бэби-театрлар форум-фестивале уза. Анда Минзәлә, Әтнә, Әлмәт, Казан, Уфа һәм Улан-Удэ театрлары катнаша. «Ләкләк» II Бөтенроссия бэби-театрлар фестивале 2024 елның май-июнь айларында кабат С. Өметбаев исемендәге Минзәлә театры базасында уздырыла. Бу юлы аның географиясе тагын да киңәя. Яр Чаллы, Ульяновск, Владимир, Йошкар-Ола, Рыбинск коллективлары да өстәлә.

Алмаз Садриев Татарстанның күп кенә театрлары белән хезмәттәшлек итә. С. Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театрында алда телгә алынган «Татар орнаменты. Тере бизәкләр»нең (2018) постановкасыннан тыш, ул – Әлмәт татар дәүләт драма театрында куелган «Әлли-бәлли» (2019), «Moroz. Space» (2020) һәм «Җир» (2021), Буа дәүләт драма театрындагы «Кем бу?» (2019), К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының «Менә сиңа куш кулым» (2022) һ. б. бэби-спектакльләрнең дә авторы.

Алмаз Садриевның иң уңышлы спектакльләренең берсе – Әлмәт театрындагы «Җир» булды. Марина Шимадина аны «идеаль бэби-спектакль» дип саный [4]. Премьерасы 2021 елның 1 июнендә була. «Җир» 0+ яшь категориясенә карый һәм 2 яшьтән алып 5 яшькә кадәр балалары булган гаиләләргә тәкъдим ителә[1]. Автор һәм режиссёр А. Садриев бу бэби-спектакльне сабыйларны Борынгы Мисыр, Греция һәм Кытай белән беренче таныштыру максатын куеп иҗат итә. Ул мавыктыргыч казу эшләре рәвешендә бара. Гап-гади комлыкта уйнаганда, геройлар – ике актёр (Энже Сәйфетдинова, Раушан Мөхәммәтҗанов) гадәти комда никадәр сер яшеренүен ачыклыйлар. Анда, мәсәлән, Мисыр пирамидасын, Давытның башын, фиргавен мумиясен яки борынгы халыкларның күп кенә башка тарих, мәдәният һәм көнкүреш әйберләрен казып чыгарырга мөмкин. Матур күренеш тамашачыларның янында гына уйнала. Ә спектакль азагында балалар актёрларга кушыла һәм, рәхәтләнеп комда казынып, алар белән бергә җир серләрен ача – кешелекнең «мәдәни катламнарын» тикшерә яки үзләренең «серчекләрен» күмеп куя алалар. Шул ук вакытта гади, аңлаешлы һәм мавыктыргыч уен формасында алар моториканы, координацияне, логиканы үстерәләр, яңа эмоциональ тәҗрибә алалар.

[1] Классик бэби-спектакльләрнең максатчан аудиториясенең яшь чикләве 0–3 яшь булса да, театрлар еш кына бу кысаны киңәйтәләр, чөнки зуррак, 4–6 яшьлек балалар да аларны мавыгып карыйлар.

Марина Шимадина «Җир»нең тагын бер үзенчәлеген билгеләп үтә: «...спектакль очень экологичен с эстетической точки зрения: мягкие естественные цвета, приятные фактуры, которые потом можно пощупать, включая и тактильные ощущения, очень важные для малышей. В сочетании с игрой света тут создаются визуальные картины, которые учат детей видеть и ценить прекрасное» [4].

Театр тәнкыйтьчесе Мила Денева фикеренчә, Алмаз Садриев бэби-театрны әнисе алдына утырган баланың күңел ачуы итеп карамаган, ул – Галәмне тикшерергә чакырган сирәк авторларның берсе. «Җир» спектакленең төп матурлыгын тәнкыйтьче болай күрә: «в непретенциозности факта искусства, зрелища, события. Все очень просто: платок с шеи артиста, четыре колышка – и вот уже китайский дракон парит над песочницей <...>. Путь познания идет от частного к общему, и из найденных в песке осколков глиняной тарелки может родиться бабочка, а может – сюжет о древних ацтеках <...>. Созданная буквально из «тряпья и палок», «Терра» четко выполняет свою задачу: раскрывает тему сотворения мира невербальным способом, дает первый опыт пассивного созерцания, а затем и активного соучастия в спектакле» [3].

Бизнес Online газетасына биргән интервьюда Алмаз Садриев үз проектының әһәмиятен түбәндәгечә бәяли: «Смысл в том, чтобы создать условия для погружения ребенка в среду взрослого искусства. И сделать это интересно. Ведь попади он просто в музей или галерею, где все статично, увиденное не вызвало бы никакого интереса. А здесь через привычную ситуацию – игру в песочнице – непонятные вещи как статуя Аполлона или другие шедевры становятся привлекательными. Это останется в подсознании, потому что станет знакомым с раннего детства» [1].

Казанда тәүге бэби-спектакльләрнең берсе «Угол» иҗат лабораториясендә Канада язучысы Николас Одленның «Бобер, который наломал дров» («Эш майтарган кондыз») китабы мотивлары буенча куелган «Деловой бобер» («Эшлекле кондыз») спектакле (2017) булды. Режиссёры һәм рәссамы Александра Ловянникованың («Бэби-Лаб» (Мәскәү) театр лабораториясе резиденты) бу вакытта инде балалар өчен спектакльләр эшләүдә катнашу тәҗрибәсе зур була. Ул 2 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге сабыйларга исәпләнгән. Бу – эшлекле кондыз турындагы әкият. Ул агачларны кимерә, аларның ботакларын сындыра һәм плотиналар төзи. Үзе белән гаҗәеп бер хәл булганчы, ни өчен шулай эшләве турында уйлап та карамый. Тегеп эшләнгән йомшак курчаклар һәм музыка уен кораллары ярдәмендә ике актёр һәм музыкант Кондыз тарихын тасвирлый. Өстәвенә, спектакльне караганнан соң, үз әкиятеңне уйлап чыгарып, аны өйдә дә уйнарга мөмкин. Мәсәлән, кайбер геройларны әти-әниләр ярдәме белән кулдан эшләргә була: оекбашлардан әкәм-төкәм яки игезәк ябалаклар ясарга, мендәрне агачка әйләндерергә мөмкин. «Угол» лабораториясенең трансформер залы спектакль вакытында вакыйга барган урынга әверелә.

Тамаша беткәч, жанр таләп иткәнчә, актёрлар нәни тамашачыларны геройлар һәм реквизитлар белән уйнарга чакыра.

Тагын бер мисал – «Әкият» Татар дәүләт академия курчак театрының «Кондызлы буа» (2022) бэби-спектакле, 1 яшьтән югары иң кечкенә тамашачылар өчен спектакль. Актёрлар нәниләрне җәйге урман һәм анда яшәүче кондыз, кама, ләкләк, энә карагы, карлыгач, буада яшәүче балыклар белән таныштыруны максат итәләр. Балалар кондызга буа буу өчен таяклар җыярга булышалар, энә каракларын һәм карлыгачларны кулларына куялар, әниләре белән урамда йөрергә чыккан үрдәк бәпкәләрен саныйлар, шаян балыкларны кире буага җибәрәләр, камага сукмак ясыйлар, ләкләкнең биюенә сокланалар, урман тынлыгын тыңлыйлар. Актёрлар – Ирина Гайнуллина, Эдгар Гайнуллин һәм Лариса Пасынкова – хәтта иң кыюсыз һәм куркак балалар белән дә бик җиңел элемтәгә керәләр, алар да уенга рәхәтләнеп катнашып китәләр, ә ахырдан кайтып китәргә теләмиләр. Спектакльне сәхнәгә театр артисты Айвар Гыймаев куйган, музыкасын Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Юрий Чаплин язган, декорацияләрне куючы рәссам Ландыш Шәрибҗанова уйлап тапкан.

«Кондызлы буа» 2022 елда «Һөнәр» XIV Бөтенроссия яшь режиссура фестивалендә күрсәтелде. Спектакльдән соң булган фикер алышуда бэби-театрның жанр үзенчәлекләре, шулай ук аның белән шөгыльләнүчеләр очрашкан «яшерен агымнар» ачыклана. Анда фестивальдә эшләгән Казан, Мәскәү һәм Санкт-Петербург тәнкыйтьчеләре катнаша. Барысы да актёрларның ягымлы-сөйкемле булуын, аларның балаларга сакчыл, оста якын килүләрен билгеләп үтәләр. Нияз Игъламов (Казан) спектакльне иҗат итүчеләрнең уйлап табу һәм сәнгатьчәлеккә күбрәк игътибар бирүләрен тели, драматургия, персонажлар арасында үзара бәйләнешнең җитенкерәмәвен ассызыклый. Глеб Ситковский (Мәскәү), киресенчә, мондый спектакльләр аерым драматургиягә мохтаҗ түгел, чөнки алар күбрәк тасвирлау характерында, аларның максаты – дөньяны ачу, дип белдерә. Әмма ул да, балалар спектаклендә тылсымның мөһимлеге турында сөйләп, максаты күңел ачу булган аниматорлыкка авышудан сакланырга куша. Бу фикерне Александр Вислов та (Мәскәү) хуплый. Владимир Кантор (Санкт-Петербург) балаларны театрның шартлы булуы һәм төрле курчаклар белән таныштыру мөһимлегенә басым ясый. Ә Жанна Зарецкая (Санкт-Петербург) финалның тәрбияви йогынтысын көчәйтергә – урманны саклау теләген конкрет уеннар белән тутырырга тәкъдим итә[1].

Спектакль турында фикер алышу шуны күрсәтә: хәтта тәҗрибәле экспертлар да бу күренешнең жанр табигатен төрлечә аңлый, ә бу бэби-театрның, театр сәнгатенең үзенчәлекле төре буларак, әле үсеш процессы гына кичерүен билгели.

---

[1] «Һөнәр» XIV Бөтенроссия яшь режиссура фестивалендә «Кондызлы буа» спектаклен тикшерүнең (18 декабрь, 2022 ел) язмасы авторда саклана.

Соңгы елларда Татарстан театрлары һәм тамашачылар тарафыннан бэби-театр белән кызыксыну арта. Бэби-спектакльләр Казан, Әлмәт, Әтнә, Минзәлә, Яр Чаллы театрлары афишаларына кертелә. Мәсәлән, «Әкият» курчак театры репертуарында гына да нәниләр өчен биш спектакль уйнала: «Доброе утро» («Хәерле иртә»), «Приключения пингвиненка Пинка» («Пингвин баласы Пинка маҗаралары»), «Бобровый пруд» («Кондызлы буа»), «Один день из жизни улитки» («Әкәм-төкәмнең бер көне»), «Добрый день» («Хәерле көн») (рус һәм татар телләрендә).

«Мастеровые» рус драма театрында (Яр Чаллы шәһәре), балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, бэби-театр өчен махсус зал җиһазландырылган. Тамаша залын һәм сәхнәне йомшак мендәрләр һәм пуфлар куелган уртак киңлек алыштыра, ул 25 нәни тамашачыны сыйдыра. Өй атмосферасы хөкем сөрә, шатлыклы төсләр, йомшак яктылык хәтта иң оялчан сабыйларны да үзләрен иркен хис итәргә, театраль күренешне рәхәтләнеп карарга һәм анда катнашырга этәрә. 2022 елдан башлап биредә Алмаз Садриев куйган «Панда булу» бэби-спектакле бара (пластика буенча режиссёр Евгений Якимов, куючы рәссам Елена Сорочайкина). Бу – сюжетсыз, конфликтсыз, текстсыз классик бэби-спектакль. Тамаша дәвамында нибары биш-алты фраза яңгырый. Ул 2 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга исәпләнгән. Спектакль нәни тамашачыларны ялыктырмый гына кытай мәдәнияте һәм Инь-Янь гармониясе белән таныштыра. Сабыйлар шаян кытай аюларының хәйләсез тормышын күзәтәләр, аларның һәрберсенең үз холкы бар (Анна Храмова, Евгения Яковлева, Виталия Борисова, Виктория Домитрак). Аюлар ялкауланалар, ауныйлар, уйныйлар, шаяралар, алар канәгать һәм бер кайгылары да юк, игелек һәм тынычлык бөркелә үзләреннән. Әлеге атмосфера музыка, яктылык һәм видеопроекцияләр ярдәмендә дә тудырыла. Гармония иң гади әйберләрдән туа, нәтиҗәдә, баштагы аклы-каралы дөнья яктылык һәм шатлык белән тула. Ахырда нәни тамашачылар геройларга кушылалар һәм үзләре дә интерактив гамәлләрдә катнашалар.

«Мастеровой»ларның бэби-спектакле сабыйларны сак кына һәм мавыктыргыч итеп театр дөньясы белән таныштыра, алар беренче тапкыр кытай мәдәниятенә якыная, уңай эмоциональ тәҗрибә һәм игелек дәресе ала. Ә бу, Алмаз Садриевның югарыда әйтелгән сүзләренә әйләнеп кайтсак, «...балачактан ук таныш булганга, мәңгегә аларның исендә калачак» [1].

Казан яшь тамашачы театрының Максим Горький әкияте буенча куелган «Воробьишко» (режиссёры Радион Букаев, рәссамы Надежда Иванова) – бэби-спектакльнең уңышлы үрнәге булып тора. Спектакль 2025 елның июлендә «Горький+Казан» сәнгать фестивалендә тәкъдим ителгән эскиздан «үсеп чыккан». Аның премьерасы 2025 елның 4 октябрендә булды. Ул 9 айлыктан 5 яшькә кадәрге балалар өчен. Анда ике актёр катнаша: Чыпчык малае ролен Нияз Зиннәтуллин башкара, Әни чыпчыкны – Дарья Бакшеева. Спектакль барышында

балалар һәм ата-аналар оя ясауда катнашалар, кошларның уеннарына тартылалар, батыр һәм шат чыпчыкның юлыккан бәладән бәхетле генә котылуына шаһит булалар. Шулай итеп, кошлар гаиләсе тормышы аша балалар гади әйберләрнең, текстураларның, формаларның һәм авазларның нәзберек һәм кызыклы дөньясы белән танышалар. Спектакльдә табигый экологик материаллар – агач, салам, кабык, тире һ. б. кулланыла. Казан яшь тамашачы театрының баш режиссёры, спектакльне сәхнәгә куючы Радион Букаев болай ди: «Сказка Максима Горького о взаимоотношениях матери и ребенка, раскрывает важность семейных ценностей и бережного отношения друг к другу. Спектакль позволяет простым языком говорить с детьми о важном. Кроме того, это прекрасная возможность погрузиться в тематику не только детям, но и родителям» [2].

«Воробьишко» 2025 елның декабрендә А.С. Пушкин исемендәге Псков академия драма театрында узган «Кроха-Фест» I Бөтенроссия нәниләр өчен спектакльләр фестивалендә катнашты. Ул нәни тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде һәм заманча процессуаль театрны бэби-спектакль бурычлары белән органик рәвештә тоташтырган өчен, жюриның махсус бүләгенә лаек булды. Фестивальнең жюри әгъзасы, театр тәнкыйтьчесе Наталия Каминская болай дип ассызыклады: «В целом весь спектакль – и в музыкальном, и в визуальном решении, и в тонкой работе актёров – прекрасно работает на детское восприятие. Это настоящий бэби-спектакль, учитывающий особенности восприятия самых маленьких зрителей. И по сегодняшней восторженной реакции малышей мы все это прочувствовали» [2].

Татарстан театрларындагы бэби-спектакльләргә кыскача гына күзәтү дә балалар өчен театрның бу яңа төрен аерып торган формаларның, сәнгать алымнарының, темаларның һәм алымнарның күптөрле булуы турында сөйли. Әмма мондый төр спектакльләр өчен мәҗбүри саналган төп жанр билгеләре дә бар. Бэби-театр бинасы төп өч принципка – сюжетсызлык, текстсызлык һәм конфликтсызлыкка нигезләнә, дидек. Калган компонентлар вариатив һәм спектакльне тудыручыларның ихтыярына һәм фантазиясенә бәйле.

Бэби-театрның үсеше тулаем Россиядә, аерым алганда Татарстанда, һәрвакыт шома гына бармый. Мәсәлән, Алмаз Садриев театрны анимация белән алыштыру куркынычын, бэби-спектакльләр иҗат итәргә алынучыларның махсус әзерлеге, критерийларның анык булмавын ассызыклый [1]. Шуңа да карамастан, тәҗрибә алга таба да бу юнәлешне үстерүнең перспективалы һәм әһәмиятле булуын күрсәтә. Баланы рухи, эмоциональ һәм эстетик яктан үстерүдән тыш, бэби-театр театр теленә сизгер тамашачыларның яңа буынын әзерли.

**Әдәбият**

1. Алмаз Садриев [Электронный ресурс]. URL: https://grandkidsfest.ru/navigator/names/rezhissery/almaz-sadriev/?ysclid=mdsit2efuu435313022 (дата обращения: 01.02.2026).

2. Бэби-спектакль «Воробьишко» Казанского ТЮЗа получил специальный приз жюри на фестивале «Кроха-фест» [Электронный ресурс]. 15 декабря 2025. URL: https://mincult.tatarstan.ru/index.htm/news/2478030.htm (дата обращения: 09.02.2026).

3. *Денёва М.* «Маршак»: мировая опера, шоу рудокопов и раскопки в песочнице [Электронный ресурс] // Петербургский театральный журнал блог. 15 апреля 2022. URL: https://ptj.spb.ru/blog/marshak-mirovaya-opera-shou-robokopov-i-raskopki-v-pesochnice/?ysclid=mdss82daiw843023419 (дата обращения: 03.02.2026).

4. *Шимадина М.* Бэби-театр по-татарски [Электронный ресурс] // Петербургский театральный журнал блог. 15 февраля 2021. URL: https://ptj.spb.ru/blog/bebi-teatr-po-tatarski/ (дата обращения: 15.01.2026).

***Шевченко Елена Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Шевченко Елена Николаевна,***
*кандидат филологических наук, доцент, старший научный сотрудник*
*Центра искусствоведения Института языка, литературы*
*и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*
*elenachev@inbox.ru*